МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИРҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

21.10.2021 Казан ш. № 3193-р

**Татарстан Республикасы Нурлат, Питрәч, Зеленодольск муниципаль районнары территориясендә газ бүлү челтәре объектының саклык зонасын урнаштыру турында**

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 статьяларына, «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, “Күчемсез милекнең дәүләт теркәве турында” 2015 елның 13 июлендәге № 218-ФЗ Федераль законның 32 статьясына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп, «Газпром газомоторное топливо» ҖЧҖ мөрәҗәгате нигезендә, «Татарстан Республикасының пространство мәгълүматлары фонды» дәүләт бюджет учреждениесе хатын (07.10.2021 № 1285/05) исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Озынлыгы 96 м.га сузылган газ бүлү объектының саклык зонасын («Татарстан Республикасы, Нурлат ш. МКПГ-1») территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүмат, газ бүлү челтәренең характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп, 380 +/- 7 кв.м. гомуми мәйданлы территория рәвешендә урнаштырырга.

2. Озынлыгы 1375 м.га сузылган газ бүлү объектының саклык зонасын («ТР, Питрәч районының Кулай авыл советында АГНКС газ тәэминатының саклык зонасы, 843 км а/ю М-7 «Волга») территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүмат, газ бүлү челтәренең характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп, 5508 +/- 26 кв.м. гомуми мәйданлы территория рәвешендә урнаштырырга.

3. Озынлыгы 378 м.га сузылган газ бүлү объектының саклык зонасын («ТР, Зеленодольск районының Осиново авыл советында АГНКС газ тәэминатының һәм юл сервисы комплексының саклык зонасы») территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүмат, газ бүлү челтәренең характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп, 1475 +/-13 кв.м. гомуми мәйданлы территория рәвешендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның 1 -3 пунктларында күрсәтелгән газ бүлү челтәрләре объектларының саклау зоналары чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән җир кишәрлекләренә газ бүлү челтәрләрен эксплуатацияләү срогына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары А.И.Галиевка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**